
Аяз Хәсәнов
Зәңгәр алан

ББК 84 (2Р-Тат)
Х 91

Аяз Хәсәнов Себердә туып үскән. Карурманлы якларда. Әкиятләрендәге Койрыксыз саескан да, авыру Поши да, агулы Чебен гөмбәсе дә — бар да аның танышларыдыр, мөгаен. Юкса, алар турында бу кадәр каян белсен икән Аяз абыегыз?!

КАЗАН
«МӘГАРИФ»
1994

Для младшего школьного возраста

Аяз Гарафиевич Хасанов

ГОЛУБАЯ ПОЛЯНА

Сказка

(на татарском языке)

Редакторлары *И. Н. Зөлкарнәева, В. Г. Гомәрова*
Тышлык рәссамы *В. Е. Булатов*
Корректоры *Ф. Х. Макарова*

ИБ № 239. Тираж 10 000 данә. Заказ А-251. С-38.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Издательство «Магариф». 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
Татарстан Республикасы газета-журналлар нәшрияты типографиясе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.

$X\frac{4803560205 - 033}{П\ 86\ (03) - 94}$ без объявл.— 94

ISBN 5-7761-0261-8

© «Мәгариф» нәшрияты, 1994



1. КОЙРЫКСЫЗ САЕСКАН

Бу иртәдә Зәңгәр алан халкын Тукран уятты. Ул алагаем юан каен кәүсәсендә утыра һәм, тук-тук итеп, бертуктаусыз агач кайрысын тукылдата. Ягъни, мәсәлән, үзенә яңа тишек тишә, өр-яңа оя ясый.

Бирегә аның беренче килүе түгел. Менә инде өч ел рәттән һаман шушы пәһлеван тирәсендә кайнаша, чөнки, башка туганнары кебек үк, ул да бер куышта ике кат оя корырга яратмый. Бала очыра да менә дигән бүлмәсен теләсә кайсы урман әһеленә калдырып китә. Әлеге каен кәүсәсендә дә аның беренче оясына сыерчыклар оялаган, икенчесендә тиеннәр гаиләсе яшәп ята. Ә Тукран исә һаман килә бу төбәккә. Яз да килә, көз дә килә:

— Тукы-тук, тукы-тук...

Яз көне каенның ап-ак кайрысын чукып, рәттән берничә тишек ясый, шуннан саркыган татлы каен суын рәхәтләнеп, ләззәтләнеп эчә. Шулай итеп, өч ел эчендә каен кәүсәсе вак-вак кына тишекләр белән тәмам чуарланып калды. Тора-бара тоташ бер билбау-путага — Тукран путасына әверелде.

— Тукы-тук, тукы-тук...

Тукран тукылдавын ишетеп, Койрыксыз саескан килеп җитте.

— Әй, Тукран-тукран, ничек томшыгыңны сындырмыйсың? — дип шыкырдарга кереште ул,— яз димисең, көз димисең, һаман чокый бирәсең. Ясаган куышың барыбер башкаларга кала. Миннән үрнәк алыр идең! Мин... Мин урманда иң акыллы, иң зирәк кош. Мин дә берьюлы ике-өч оя корам. Ләкин аларның тик берәүсе чын оя. Калганнары күз буяу өчен генә, тәк шунда, аркылы-торкылы чыбык-чабык. Беркем дә үзләштерә алмый. Ә син! Гомерең буе тукы-тукы. Аптырарсың бу эшкә! Нишләп сине иң акыллы кош дип йөртәләрдер!

— Әй, Койрыксыз саескан,— диде Тукран,— шулай бик белдекле булганга койрыксыз калгансың, мөгаен! Сыпыр, комачаулап утырма. Юкса, синең дә баш түбәңә тишек тишеп җибәрермен.

— Кара-кара! Җитмәсә әле тупас та икәнсең, тукылдык! — диде Саескан.— Ни майтарган диярсең. Бөтенесе эшем кешесе! Рәхәтләнеп бер сөйләшермен димә! Юкса, мин урманда бөтен яңалыкны белеп торам.

Саескан шыкырдый-шыкырдый очып китте. Озакламый нәни тычкан оясы янына барып, тәрәзә шакыды:

— Күрше, күрше! Әллә йоклап ятасың инде.

Йокылы күзләрен уа-уа, оядан Тычкан килеп чыкты.

— Хәерле иртә, Саескан күрше. Яңалыклар юкмы?

— Булмаган кая. Мин бар халыктан иртә торам, барысын да күрәм, барысын да ишетәм, сезгә сөйләп бирәм. Миндәге яңалык бер букча! Узган төн таңга кадәр Ябалак ухылдап йөрде...

Ябалак исемен ишеткәч, нәни Тычкан дер калтырый башлады.

– Күке миләш чыпчыгын кызык итте, оясына үз йомыркасын салып китте. Кондыз су буендагы усакны кимереп аударды.

– Ә теге... Рәхимсез Ябалак нишләде?– дип сорады Тычкан.

–...Куян аягын яралады, Төлке-төләнби бөгәрләнеп яткан Керпене урман инешенә тәгәрәтеп төшерде, аны әнәсе-ние белән кабып йотарга исәпләде. Керпе теге як ярга йөзеп чыгып кына котылды,– дип, үз туксанын туксанлады Саескан.

– Ул Ябалак мәлгунь минем әбиемнең бабасын...– диде Тычкан, кайгысын уртаклашырга теләп. Ләкин Саескан аның зарына колак та салмады.

– Күл буенда Аю-Ахун үзенең улын төпәләп ташлады. Мин урман каравылчысының көчеген кызык иттем, авызыннан ипиен алып киттем...

– Узган ел ул акай күз мине дә чак-чак кабып йотмады,– диде Тычкан, дер-дер калтыранып.

– Тукран тагын үз эшендә, – дип дәвам итте Саескан.– Һаман тукый, һаман тукый. Бөтен агачларны бозып бетерә...

Ниһаять, нәни Тычканның түземе төкәнде. Ул Саесканга мыскыллы караш төшереп алды да, җеп койрыгын селтәп, оясына кереп китте.

–Кара-кара!..– дип шыркылдады Саескан.– Сүземне дә тыңлап бетермәде юньсез, әдәпсез, килбәтсез! Кара-кара!..

2. МӘКЕРЛЕ КАРАК

Саескан бөтен урманны кичте, бар булган яңалыкларын, бөтен уйдырма-гайбәтләрен сөйләп бетерде. Ләкин аны берәү дә юньләп тыңламады. Һәммәсе дә үз эшендә иде.

Шуннан, Саесканның эче поша башлады. Инде нишләргә?

«Урман каравылчысы ихатасына барып килим әле булмаса,– дип уйлады ул.– Теге тинтәк көчекне тагын алдалап булмасмы?»

Урман аша шактый очып баргач, Саескан ял итәргә агач төбенә кунды.

Караса, әлеге агач төбе янәшәсендәге үләннәр кыштырдап-кыштырдап куя. Ни булыр?

Койрыксыз саескан җәһәт кенә җиргә сикереп төште, кача-поса якынлаша башлады. Әмма шунда ул кинәт куркуга калды... Әгәр... Әгәренки үлән арасында бер-бер куркыныч ерткыч җанвар посып ятса? Әбәдкә берәр аңгыра кош очып килмәсме, дип көтеп тора торган булса?..

– Әй, син! – дип кычкырды Саескан, гайрәт күрсәтергә тырышып. – Чык исән чагында. Юкса, хәзер очып кунам да ботарлап ташлыйм үзеңне!

Үләннәр тагын да катырак кыштырдап куйды, кемдер мыш-мыш килде, тып-тып тыпылдады. Саескан тәмам каушап калды. Шунда, үләннәрне аралап, Керпе килеп чыкты, авызын зур ачып, иснәп куйды.

– У-уф! – дип, иркен сулады Саескан.– Нәрсә син, Керпе, кешенең котын алып... Тукта әле, тукта, сине Төлке кабып йотмадымыни?

Керпе тагын авызын тутырып иснәде, күзләрен угалады:

– Төлкеме? Төлке синең кебек үк аңгыра мәхлук ул, Саескан.

– Гөрбиян! – дип кычкырып җибәрде Саескан.– Әнәле түмәр! Беләсең килсә, мин урманда иң акыллы кош.

– Гөрбиян! Әйдә, такылда, бушбугаз,– дип кул селтәде Керпе.– Бар әйдә, сата бир гайбәтеңне. Минем йокы килә...

Ул шунда ук йомгактай йомарланды да йокыга да китте.

– Һи, кыяфәтсез!

Саескан, нарат күркәсе алып, Керпегә томырды да янәдән очып китте.

Менә ул каравылчы ихатасына да барып җитте. Беркем күренми. Тик кечкенә Сарбай гына оясы янында йокымсырап ята. Алдында калай табак, табакта сөяк. Кимерелмәгән! Әле иртән генә чыгарып салганнар, күрәсең!.. Саесканның авызыннан сулар килде. Менә, ичмасам, эләктерсәң!

Ләкин Сарбай уяу иде.

– Нихәл, Койрыксыз! – дип ырылдады ул, яткан җиреннән сыңар күзен генә ачып.– Сыпыр әле яхшы чакта. Юкса, булыр-булмас койрыгыңны да кабып өзәрмен. Күрәм, минем сөяккә күз кыздырып йөрисең.

– Фи! Исем китте! – дип томшыгын кыйшайтты Саескан. Әмма Сарбай бу койрыксыз каракның гадәтләрен яхшы белә иде. Ялт кына сикереп торды да сөяген оясының түренә үк кертеп куйды.

– Миндә андый сөякләр меңләгән,– дип дәвам итте Саескан.

– Синекеннән шәбрәкләре дә сарай салырлык. Ә синеке... Чукысаң, томшыгыңны сындырырсың!

Бу сүзләрне ишеткәч, Сарбайның күзләре ут янды.

— Чынлапмы? Шулай күпме? Кая?

— Беләсең килә икән! Әйттем ди менә, хәзер! — Саескан, ваемсыз кыяфәт белән, читкә борылып утырды. Әмма бер күзе һаман Сарбайда иде.— Хәер... әйтсәм әйтим инде. Дус итеп кенә. Әйдә, калма минем арттан.

Койрыксыз саескан күккә күтәрелде, Сарбай, сикереп торып, аның артыннан йөгерде.

— Әнә! Әнә күрәсеңме теге аландагы кәкре каенны,— дип кычкырды Саескан.— Каен төбендә минем оя, шул ояда бер өем сөяк!

Сарбай өзә-каба кәкре каен ягына чапты. Саесканга исә шул гына кирәк иде. Ул тиз генә каравылчы ихатасына әйләнеп кайтты, эт оясыннан теге сөякне алып чыкты һәм шунда ук кәкре каен янына очып килде.

Сарбай исә, иснәнә-иснәнә, агач төбендәге хәзинәле ояны эзли иде.

Койрыксыз карак каен ботагына барып кунды да Сарбайга мәкерле караш ташлады:

— Йә, сизгер көчек, таптыңмы минем хәзинәне?

Сарбай башын югары күтәрде. Караса, ни күрсен, аның теш тә тимәгән майлы сөяге карак Саескан тырнагында!

Күзеннән яшьләр атылып чыкты бичара маэмайның.

— Койрыксыз ялганчы! — дип мышкылдады Сарбай һәм, башын иеп, койрыгын җирдән сөйрәп, өенә юнәлде.

Ә Саескан ул арада сөякне чистартып та ташлаган иде инде. Һәм, үтә канәгать кыяфәт белән, бөтен урманга шар яра, очраган бер җәнлеккә Сарбайны ничек алдавы турында мактана иде.

3. ЧЕБЕН ГӨМБӘСЕ ҺӘМ ПОШИ

Койрыксыз саескан эш югыннан аптырап, усак ботагында утыра. Ә түбәндә, тар гына сукмак кырында, Чебен гөмбәсе үсә. Инде шактый зур үскән, әмма аны беркем дә алырга теләми. Гөмбә исә үскән саен усаллана бара. Сукмактан узучы һәркемнең күзенә чалынырга тырыша. Тик юкка гына... Барысы да аны әйләнеп уза. Чөнки аның зәһәр агуыннан куркалар.

– Саескан! Әй, Саескан! – дип дәште Чебен гөмбәсе.– Синең әле мине татып караганың юктыр.

– Татырга да теләмим синең ише кызыл кыбырсыкны,– дип читкә төкерде Саескан.

– Ә менә башында акылы булган кошлар мине бик тәмле дип әйтәләр. Усак гөмбәсе белән баллы гөмбә генә, миннән көнләшеп, яман атымны саталар. Агулы, имеш. Ә чын дөресен әйткәндә, миннән матур, миннән тәмле гөмбәне эзләп тә таба алмассың.

Чебен гөмбәсе теттереп үзен-үзе мактый һәм шул арада Саесканга күз төшереп ала. Ышанамы-юкмы, янәсе.

– Сайра, чибәрем, сайра! – дип көлде Саескан...– Әнә Тиен күрше, сине кышка киптереп куям дип, бер генә кабып караган иде, шунда ук әтәч булып кычкыра башлады. Эче борганга чыдаша алмыйча. Син хәерсездән ераграк булуың яхшы.

Саескан, утырган ботагыннан кубып, өскәрәк күчеп утырды.

Шул вакыт борылып караса... Сукмак буйлап Поши килә. Чайкала, аякларын чак-чак атлый. Авырый икән, бичара! Бөтен урман җәнлекләре дәваларга тырышканнар. Куян кишер алып килә икән, Тукран – нарат күркәсе, Керпе пешкән алма китерә.

Һичберсе ярдәм итми. Менә шулай авыру килеш каңгырып йөри урман пәһлеваны. Аны күрүгә, Чебен гөмбәсе, күзенә керердәй булып, муенын сузды. Ә Поши исә ка-апылт! Капты да йотты шул зәһәр пышлакны. Саескан куркуыннан чаккына мәтәлеп төшми калды. Поши чайкала-чайкала күл ягына китеп бара иде.

— Ой-ой-ой,— дип кычкырып җибәрде Саескан,— ой-ой-ой... Ух-ух-ух!.. Җәмәгать! Чебен гөмбәсе Пошины ашады... Пошины кабып йотты. Үз күзләрем белән күрдем. Пошины харап итте!

— Нәрсә-нәрсә? — дип кычкырды Тукран.— Кемне кабып йотты Чебен гөмбәсе.

— Юк-ла, гөмбә түгел, Поши агулы гөмбә ашады. Капты да йотты. Сүз әйтергә дә өлгерә алмый калдым. Әнә, күл ягына китте. Шунда батып үләргә ниятләп китте. Кар-равыл! Коткарырга кирәк бичараны, коткарырга!..

Койрыксыз саескан бөтен урманга сөрән салды, бөтен җан ияләренең котын алды. Урманда мәхшәр купты. Борындыклар, тиеннәр, куяннар, төлкеләр — барча киек-җанвар, барча кош-корт күл ягына ташландылар. Койрыксыз саескан исә бөтенесеннән алда бара һәм туктаусыз шыркылдый:

— Тизрәк-тизрәк! Бата, харап була! Коткарыгыз-коткар-р-р! Килеп җитсәләр, ни күрсеннәр: Поши күл уртасына ук кереп баткан. Борыны гына күренеп тора. Йөзеп чыгарга да омтыла кебек. Пошкыра, куыклар чыгара, су чәчрәтә...

Саескан аның турына кадәр үк очып керде, канатларын еш-еш җилпеп, бер урында тукталып калды:

— Ке-регез! Суга! Суга! Коткар-р-рыгыз!

Куян балалары яр буеннан кул изилəр, түземсезлəнеп сикерəлəр, ары-бире йөгерəлəр:

– Монда! Монда! Ярга таба иш!..

– Тагын! Тагын бераз! – дип, куəт бирə Саескан.

Урман табибе Бурсык та килеп җиткəн. Ул, кул сумкасын ачып, чирəм өстенə төрле даруларын, градусникларын тезə.

Менə Поши йөзеп килеп җитте, яр буена чыкты, селкенеп, өстеннəн суын какты. Аннары, тəмам өнсез калган җəнлеклəрне күреп, шаккатты:

– Ни булды сезгə? Нигə җыелдыгыз?

– Син... Син Чебен гөмбəсе ашаган идең түгелме соң? – диде Саескан.

– Ашадым. Шуннан ни булган?

– Соң... Соң шулай булгач...– дип шыкырдый бирде Саескан.– Шулай булгач, сине коткарырга кирəк ласа...

– Э-э, нəрсə сез, җəмəгать! – дип көлде Поши.– Чебен гөмбəсе минем өчен иң шəп дару. Шуны йоту белəн җиңел булып китте менə. Су да коенып алгач, бөтенлəй терелдем.

Бөтен җəнлек-җанварлар, кош-кортлар аптыраштан беразга катып калдылар. Шунда нəни Куян сикереп алга чыкты:

– Əйдəгез алайса Зəңгəр аланга. Сикерербез, уйнарбыз, чəчəклəр исен иснəрбез!

– Ботактан-ботакка очарбыз,– диде Тиен.

– Качышлы уйнарбыз! – дип өстəде Тычкан.

– Мəтəлчек атарбыз...

– Таган атынырбыз...

Барысы да шау-шу килделəр, куаныштылар.

Тик Койрыксыз саескан гына, башын түбəн иеп, усак ботагында утыра иде.

Менə бит, шул лыкылдык теле аркасында, тагын хурлыкка калды.

4. УРМАНГА КЫШ БАБАЙ КИЛДЕ

Көннәрдән бер көнне Зәңгәр аланга Кыш бабай килеп төште. Шундый шат, шундый шаян бабай. Йөнтәс бүреген салып, кырмыска оясы өстенә каплады, сакал-мыекларын тузгытып җибәрде, шаярып, урман җәнлекләрен чеметкәләде. Нәни куяннар, җылынырга тырышып, тыпыр-тыпыр биеделәр, мәтәлчек аттылар, колакларын угаладылар. Акыллы кош Тукран, агач куышында тимерче алачыгы ачып җибәрде, тук-тук итеп, нарат күркәләре ярды, орлыгы белән Тиенне дә сыйлады.

Әмма бу кичнең зәңгәр тынлыгын Койрыксыз саескан чәлпәрәмә китерде.

— Тра-та-та-та! Ой-ой-ой! Ишеттегезме әле? Күрдегезме? Тра-та-та, ой-ой-ой... Мин нәрсәләр күрдем, нәрсәләр белдем...

— Ни булды? Сөйлә инде тизрәк,— дип кычкырды Тычкан.

— Әллә... Әллә урманга аучы килгәнме? — дип калтыранды Тиен.

— Карчыга килмәгәндер бит? — дип муенын җыерды Чыпчык.

Куяннар, куркынып, ялт-йолт карандылар.

— Бүреме? Кая, кайсы яктан?..

— Шул акай күз Ябалактыр инде,— дип чи-чи килде Тычкан.

— Фи! Бөтенесенең үз туксаны туксан! — диде Саескан, һаваланып.

— Кыш бабай килә, бик беләсегез килсә, Кыш бабай! Суык бабай!

— Кыш бабай? — дип сорадылар җәнлекләр, гаҗәпкә калып.— Кем соң ул Кыш бабай—Суык бабай?

— Эх сез, тиле башлар, шуны да белмисезме? — дип шаркылдап көлде Саескан.— Кыш бабай ул... Шундый дәү! Аю кебек. Үзе көрәктәй сакаллы.

— Бик куркынычмы соң ул? Усалмы? Тешләшмиме? — дип шаулаштылар җанварлар.

— Хи-хи-хи! — дип көлде Саескан, барсыннан белдекле кыланып,— Кыш бабаймы усал?! Ул капчыгы белән төрле бүләкләр алып килә. Минем кише акыллы кошларга бушлай өләшә. Ә сиңа, Чыпчык, бүләк эләкмәячәк, чөнки син аңгыра, тинтәк. Кыяфәтең дә каракныкына охшаган.

— Ә миңа? Ә миңа? — дип кызыксынды Тиен.

— Сиңа да юк,— дип көлде Саескан. Синең дә акыл ягы чамалы. Гомумән, сезнең арада акыллы җан иясе юк. Бер Тукран бераз уйларга сәләтле дисәң, анысы да шыр тиле! Бер мин генә!.. Мин генә акыллы кош, зирәк кош!

— Ә... ә нәрсә бүләк итәчәк соң сиңа Кыш бабай? — дип кызыксынды Тычкан.

— Ма-машина! — дип күкрәк киерде Саескан.— Шундый зур машина. Аңа утырып мин бөтен урманны гизәрмен, гөмбәләрне таптап изәрмен, сезне акчага гына утыртырмын.

Шул вакыт кинәт урман өстендә:

— Кар-р-р! — дигән аваз яңгырады. Күтәрелеп карасалар, имән башына Ала карга килеп кунган икән. Кыш бабайдан хәбәрче булып килгән.

— Шулаймыни? Килеп тә җитәмени? — дип тыз-быз килде Койрыксыз саескан. — Ә мин... Мин чәчемне дә тарамаган. Тоткарлап торыгыз беразга, ишетәсезме?

Ләкин Кыш бабай беркемнән дә рөхсәт сорап тормады. Салкын ак томан булып килде, көмеш бәс булып, агач ботакларына сарылды. Аннары ак сакал-

лы, ак тунлы, зур гәүдәле мөлаем бабайга әверелде.

— Йә, җәнлекләрем, кошларым, ничек яшисез? — дип елмайды ул, урман халкына карап.

Шунда әйтерсең бөтен урманны балкытып кояш чыкты. Барысына да бик-бик күңелле булып китте.

Кыш бабай, дәү капчыгын чишеп, бүләкләрен чыгара башлады. Шунда ук әрсез Саескан очып килеп җитте.

— Миңа! Миңа! — дип кычкырды ул, Кыш бабай кулындагы бүләк сыбызгыны күргәч. Әмма Кыш бабай сыбызгыны Чыпчыкка бирде.

— Ә миңа? Ә миңа,— дип дәгъваләште Саескан.

Ә Кыш бабай әйтерсең аны күрми дә. Уңга-сулга бүләкләр өләшә. Куянга — барабан, Тукранга — пәке, Тиенгә — зонтик, Тычканга — быргы... Өләшә дә өләшә.

Үзенә өлеш чыкмагач, Саескан тәмам нәүмиз булып, бер читкә барып кунды. Хурланудан, аның күзенә яшь бәреп чыкты.

Шунда нәни Куян түзмәде, кыяр-кыймас кына Кыш бабайның тун җиңенә кагылды:

— Бабай! Бабакай, ә Саесканга нәрсә?

— Ә, Саескан өлешсез калдымыни әле? — дип хәйләкәр генә елмайды Кыш бабай.— Ничек соң, балалар, сезнеңчә ничек? Бүләк тиешме Саесканга?

— Тиеш-тиеш,— дип кычкырды Тычкан.

— Мин үземнең сыбызгымны бирәм,— дип чыркылдады Чыпчык.

— Мин — барабанымны...

— Мин — пәкемне...

Шунда Саескан башын тагын да түбәнрәк иде. Үзенең ялгышларын, урман киекләренең кече күңелле икәнен аңлап алды ул. Кабат беркайчан да туганнарын җәберләмәскә, кимсетмәскә күңеленнән кат-кат антлар итте.

— Йә, ярый, алайса, монда аңа да бүләк калган икән әле,— диде Кыш бабай һәм капчыгыннан искиткеч матур зәңгәр шар чыгарып бирде.

Саескан шатлыгыннан нишләргә дә белмәде. Ул үзенең зәңгәр шарын бөтен халык күз алдына, пәһлеван каен ботагына элеп куйды. Шунда бөтен урман өстенә сыек зәңгәр яктылык таралды, ниндидер тылсымлы нурлар уйнады, күзләр камашты. Тагын Кыш бабайның басынкы юан авазы яңгырап китте:

— Бу әкият... Бу тылсымлы әкият барыгызга да уртак бүләгем булсын. Бөтен кыш буе сезнең уртак йортыгыз — урманны зәңгәр нурларга бизәп торыр, ә яз җиткәч, тамчылар булып тамар, гөрләвекләр булып агар. Хушыгыз, балалар! Мине башка урманнарда да көтәләр.

Кыш бабай шунда ак томанга әверелде дә урман өслэтеп салмак кына йөзеп китте. Урман аланында, тылсымлы зәңгәр яктылыкта, зур бәйрәм башланды.



